| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ<br>ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04 июль 2023 ел № 5755

Башкарма комитетның 2016 елның 21 гыйнварындагы 187 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең Социаль-икътисадый үсеш стратегиясен эшләү, төзәтмәләр кертү, иҗтимагый фикер алышу, мониторинглау һәм контрольдә тоту тәртибенә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Законы , Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2016 елның 21 гыйнварындагы 187 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең Социаль-икътисадый үсеш стратегиясен эшләү, төзәтмәләр кертү, иҗтимагый фикер алышу, мониторинглау һәм контрольдә тоту тәртибенең 4 пунктына, «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетының икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе башлыгы Г.В. Гыйләҗевага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов